ПӘНҖЕШӘМБЕ
11 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 9 (5809)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

МАССОВЫЙ ОБОРОНА ЭШЕНӘ БОЛЬШЕВИСТИК КОЛАЧ

ВКП(б) ның XVIII нче съезды илебез алдына, барлык совет халкы алдына СССР ның оборона куәтен тагын да ныгыту буенча тарихи бурычлар куйды. Бөек совет халкы иптәш Сталин докладында һәм XVIII нче съездның тарихи карарларында күрсәтелгән бу әһәмиятле бурычны зур активлык һәм энтузиазм белән башкара. Патриотик хисләр белән тулган хезмәт ияләре хәрби эшкә өйрәнәләр, сугыш техникасын үзләштерәләр.

Республикабызның меңнәрчә кешеләре Осоавиахим һәм Кызыл Хач җәмгыяте сафларына керәләр. Алар, төз атучы булырга, кавалерист булырга, пулеметны, танкны, самолетны үзләштерүгә омтылалар.

Хезмәт ияләренең патриотик күтәрелешләрен күрсәтә торган йөзләрчә фактлар китерергә мөмкин. Бу—республикабызның районнарында массовый-оборона оешмалары челтәре бер туктаусыз үсә барудан да бик ачык күренә. Мәсәлән, Мөслим районының барлык колхозларында, учреждениеләрендә массовый-оборона оешмалары оештырылган. Бу районда Осоавиахимның 72 башлангыч оешмасы бар, аларда 2.023 кеше член булып тора.

Буа районында ВКП(б) райкомының хәрби бүлеге җитәкчелегендә массовый - оборона эшләре киң колач алды. Оборона эшенә җитәкчелек итү өчен күп санлы кадрлар хәзерләнде. 124 кеше массовый-оборона оешмаларында җитәкче эшләрдә эшлиләр. Массовый - оборона оешмасы тирәсенә актив тупланды. Хәрби бүлек оборона активистларының җыелышларын, киңәшмәләрен үткәрә, алар белән беседалар, консультацияләр оештыра.

Бу районда оборона түгәрәкләре системалы эш алып баралар. 1939 нчы елда 1.507 кеше оборона значокларына нормалар тапшырды. Хәзерге вакытта район буенча 97 урында массовый-оборона түгәрәкләре эшлиләр. Бу түгәрәкләрдә тагын йөзләрчә яңа кешеләр оборона значокларына нормалар тапшыруга хәзерләнәләр.

Хәрби бүлек чираттагы призывны үткәрү өчен ныклы хәзерлек алып бара. Призывниклар арасында политик-масса һәм оборона эшләре киң җәелдерелде.

Республикабызда массовый-оборона оешмалары челтәре көннән-көн җәелә һәм аларның эшләре дә яхшырганнан-яхшыра бара. Хезмәт ияләренең хәрби эшне өйрәнү теләкләре гаять зур. Ләкин аларның патриотлык теләкләрен канәгатьләндерүгә, массовый-оборона эшләренә тиешенчә игтибар биреп җиткермәүче партоешмалар да юк түгел әле.

Мәсәлән, ВКП(б) ның Сарман райкомы массовый - оборона эшләре белән ныклап кызыксынмый. Бу районда Осоавиахимның 54 башлангыч оешмасы бар, ә шуларның 50 сендә бер төрле дә эш алып барылмый. Осоавиахим оешмалары таркалу хәленә килеп җиткәннәр. Ул оешмаларны ныгыту, аларда оборона эшләрен оештыру турында кайгыртучы юк.

ВКП(б) ның Югары Ослан райкомы хәрби бүлеге оборона оешмаларына тиешенчә җитәкчелек итми. Массовый-оборона оешмаларындагы җитешсезлекләрне бетерү һәм аларның эшләрен яхшырту турында кайгыртмый. Осоавиахимның район Советының пленум утырышлары булганы юк.

Кайбер районнарда оборона оешмалары кадрларына җиңелчә караш фактлары да юк түгел. Мәсәлән, Минзәлә районында бер ай эчендә Осоавиахим район советының председателе ике тапкыр алмаштырылган. Моның кебек фактлар Кузнечиха һәм Заинск районнарында да бар.

ВКП(б) райкомнары һәм аларның хәрби бүлекләре массовый-оборона оешмаларына җидди игтибар итәргә һәм бу мөһим эш белән системалы рәвештә шөгыльләнергә тиешләр. Массовый-оборона оешмаларының эшләре хезмәт ияләренең таләпләрен канәгатьләндерерлек итеп оештырылырга тиеш. „Осоавиахим—массовый ирекле җәмагат оешмасы, ул зур һәм файдалы эш алып бара. Бу оешма эшчеләрне, хезмәткәрләрне, интеллигентларны, укучыларны һәм колхозчыларны дәүләт оборонасы өчен хәзерләргә тиеш. Бер үк вакытта Осоавиахим төрле хәрби специальностьлардагы кадрларны хәзерләү буенча башлангыч эшне алып баруда Кызыл Армиягә ярдәм итә“ (К. Ворошилов).

Киң Ватаныбызның хезмәт ияләре Осоавиахим оешмалары ярдәме белән хәрби эшкә—төз атарга, маскировкага, штыйк сугышларына, гранаталар ыргытырга, чаңгыда йөрергә, санитария эшләренә өйрәнергә тиешләр. Осоавиахим оешмаларының бурычы—массаның бу теләкләрен канәгатьләндерүне тәэмин итүдән гыйбарәт. Массовый-оборона оешмаларын булдыклы кадрлар белән тәэмин итәргә, аларны политик яктан тәрбияләргә һәм чыныктырырга, аларга көндәлек эшләрендә даими булышлык күрсәтергә кирәк. Хезмәт ияләре арасында политик-масса эшләрен көчәйтү нигезендә, оборона оешмалары челтәрен тагын да киң җәелдерүгә, түгәрәкләрнең тагын да яхшырак эшләүләренә ирешергә кирәк.

„... Безнең Кызыл Армиябезне, Кызыл флотыбызны, кызыл авиациябезне, Осоавиахимыбызны бөтен чаралар белән көчәйтергә һәм ныгытырга кирәк. Сугыш һөҗүме куркынычы каршында безнең бөтен халкыбызны мобилизацион хәзерлек хәлендә тотарга кирәк, бер нинди дә „очраклылык“ һәм безнең тышкы дошманнарыбызның бер нинди дә фокуслары безне көтелмәгән хәл алдында калдырырлык булмасын...“. Осоавиахим һәм башка оборона оешмаларының эшләре иптәш Сталинның менә шушы тарихи күрсәтмәләрен тулысынча үтәрлек итеп оештырылсын.

ДАНЛЫКЛЫ КАРАБ

...1912 нче елны күренекле рус морягы, Азов балыкчысы улы, Георгий Яковлевич Седов „Св. Фока“ пароходында Архангельскидан Төньяк Котыпка китте. Бу начар пароходның Франц Иосиф җире ярларына җитүенә бозлар комачауладылар. Седов Яңа Җирдә кышларга мәҗбүр булды. Икенче елда гына ул Тихая бухтасына үтеп чыкты. Моннан Седов этләр җигелгән чаналарда Котыпка барырга кыю омтылыш ясады. Цынга белән авырган Георгий Яковлевич, матрос Линник һәм Пустошныйлар белән бергә, 1914 нче елның 15 нче февралендә „Св. Фока“ пароходы торган Тихая бухтасыннан төньякка юнәлде. Авыру аны аяктан екты. Ярым тере килеш, эт җигелгән чаналарда барганда, ул төньякка хәрәкәтне туктатмаска приказ бирде һәм туңган кулындагы компас белән үз приказының үтәлүен күзәтте. 1914 нче елның 5 нче мартында Седов үлде. Аның юлдашлары үзләренең карабы тукталган урынга көчкә генә әйләнеп кайта алдылар. Патша хөкүмәте, арктика далаларын куркусыз тикшерүченең исмен оныту өчен кулыннан килгәннең бөтенесен эшләде. Ләкин халык, Георгий Яковлевич Седов турындагы истәлекне саклап, үзенең батыр улын оныта алмады һәм реакциячеләрнең каршылык күрсәтүләренә дә карамастан рус карабы аның исме белән аталды.

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходының зур һәм данлыклы тарихы бар.

Төньяк диңгезләрендәге гүзәл рейсләр көннәрендә ул дан казанды. Большевиклар Совет җиренең төньяк кырыйларында тормышны торгыза башлагач, „Седов“ портлар һәм кышлау урыннары арасында йөреп торды.

1926 нчы елның язында „Седов“ бозваткыч флотның башка судолары белән бергә, Ак диңгез тамагында диңгез җәнлекләре аулау буенча зур эш үткәрде.

1928 нче елның июлендә „Седов“ Архангельскидагы судоремонт заводы „Красная Кузница“ның судноларны бәйләп куя торган стенасы янында ремонтта торды. Совет хөкүмәтенең карары буенча караб Италиянең арктика экспедициясенең Шпицбергеннан төньякка таба авариягә очраган „Италия“ дирижабленең экипажын эзләргә җибәрелгән иде. Зур районны тикшереп эзләп, „Седов“ Яңа Җирнең иң төньяк чиге булган Желание мысын әйләнеп чыкты.

Бозваткыч „Седов“ пароходы 1929 нчы елны мактаулы зур эшне башкарды. Караб беренче Совет фәнни-тикшеренү станциясе кышлаучыларын Гукерат авына илтеп куйды. Франц Иосиф җире өстендә Советлар Союзының кызыл флагы җилферди башлады.

1930 нчы елны „Седов“ тарафыннан гүзәл рейс башкарылды.

Төньяк җиргә бару юлында өч атау табылды. Төньяк җир архипелагы өстендә СССР ның дәүләт флагы күтәрелде.

„Седов“ Төньяк диңгез юлындагы һәрбер навигациядә өзлексез катнаша.

1937 нче елны караб гидрология күзәтүләре өчен Лаптевлар диңгезенә, Новосибирск атаулары районына китте. Лаптевлар диңгезендә ул 1937 нче елның 23 нче октябрендә бозлар хәрәкәтенә эләкте.

Хәзер совет кешеләренең тагын бер күренекле җиңүе данлыклы котып морякларының—героик совет халкының иң яхшы улларының фәнни батырлык эше „Седов“ бозваткыч пароходының исме белән бәйләнде. (ТАСС).



„Седов“ бозваткычының капитаны К. С. Бадигин.

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш В. М. Молотовка Болгариянең экономик делегациясе председателе Божилов әфәнденең телеграммасы

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе—В. М. Молотовка

МОСКВА

ТИРАСПОЛЬ.

Сәүдә һәм диңгездә йөрү турында договор һәм товар әйләнеше турында килешү төзү буенча сөйләшүләрдә,—ике арада урнаштырылган экономик хезмәттәшлек ярдәме белән Советлар Союзы һәм Болгария арасында алардагы халыклар файдасына дуслыкны ныгыта алачак сөйләшүләрдә ССР Союзы хөкүмәте тарафыннан безгә күрсәтелгән кыйммәтле булышлык өчен Болгариянең экономик делегациясе исменнән Сезгә, Советлар Союзы чикләреннән чыгып киткән вакытта тагын бер кат чын күңелдән рәхмәт белдерүне үземнең бурычым дип саныйм.

Болгариянең экономик делегациясе председателе
финанс министре БОЖИЛОВ.

Болгариянең экономик делегациясе председателе, Болгариянең финанс министре Божилов әфәндегә иптәш В. М. Молотовның телеграммасы

Болгариянең финанс министре Божиловка

СОФИЯ

Министр әфәнде, Сезнең актив катнашуыгызда Болгария белән Советлар Союзы арасында сәүдә килешүенең уңышлы төзелүе уңае белән Сезнең дусларча котлавыгыз өчен һәм белдергән хисләрегез өчен Сезгә бик рәхмәт. Безнең илләребез арасында экономик яктан якын хезмәттәшлек урнаштырылу Болгария һәм СССР халыклары дуслыгының ныгуына һәм аларның яхшы тормышларына—шушы бик әһәмиятле эшкә хезмәт итәр дип ныклы ышаныч белдерәм.

МОЛОТОВ.

„Седов“ның фәнни материалларын өйрәнү

„Седов“ бозваткычының батыр моряклары үзләренең Арктиканы күренекле тикшерүчеләр икәнлекләрен күрсәттеләр.

Илебезнең фәнни работниклары хәрәкәттәге суднодан радио аша тапшырылган кыскача белдерүләренең һәрбер юлын тәэсирләнү белән укып бардылар. Институтларда бу белдерүләр җентекләп өйрәнелделәр. СССР фәннәр Академиясенең член-корреспонденты орденлы профессор В. Ю. Визе болай ди:

„Седов“та һәм „Фрам“ да башкарылган күзәтүләрне чагыштыру җирдә һаваның үзгәреп торуы мәсьәләсе буенча гадәттән тыш әһәмиятле яңа нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирер. „Седов“тан тапшырылган кыска белдерүләр нигезендә без хәзер үк инде котып бессейнында бозлар хәрәкәтенең 1937—1939 нчы еллардагы тизлеге 1893—1896 нчы еллардагы тизлектән кимендә 50 процент артканлыгын беләбез. Бу—соңгы елларда котып бассейнының бозлардан арынуы көчле рәвештә бара дигән сүз. Арктикада бозларның гомуми күләме елдан-ел кими бара. Бу хәл соңгы ун ел эчендә күп сандагы Совет экспедицияләре тарафыннан билгеләп үтелгәнчә, Арктика диңгезләрендә бозларның төньякка таба чигенүе белән тулысынча туры килә.

Арктика институты (Ленинградта) седовчыларның материаллары нигезендә котып бассейнының тирәнлекләре, су өстендәге һәм тирәндәге агымнар турында, гомуми гидрология режимы турында кинрәк мәглүматлар алырга уйлый. Беренче алынган материаллар Үзәк Арктикада соңгы ун ел эчендә елыну башланганлыкны хәзер үк расларга нигез бирәләр. Седовчылар билгеләгәнчә, һаваның температурасы, „Фрам“ хәрәкәте вактындагыдан уртача 6 градус югарырак булып чыкты. Бозның калынлыгы да кимегән.

Арктика институты работниклары котып бассейны карталарында диңгез тирәнлекләрен дөрес билгеләрләр, боз режимы турында дөресрәк материаллар төзерләр. Төньяк диңгез юлын тәмам үзләштерүгә бу шактый зур ярдәм итәр.

Седовчыларның материалларын эшкәртү буенча хәзер конкрет чаралар билгеләнде. Институтның гыйлми советында иптәш Буйницкийның докладын тыңларга карар бирелде. Седовчыларның материалларын эшләүгә экспедициядә катнашучыларның берничәсен тартырга уйланыла. (ТАСС).

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

9 нчы гыйнварда **Ухта** юнәлешендә пехота частьләренең сугышлары булды. Сугышлар нәтиҗәсендә безнең частьләр Суомуссалмидан көнчыгышка таба берничә километрга киттеләр. **Реболы һәм Петрозаводск** юнәлешләрендә—разведка отрядларының хәрәкәте. **Карелия бугазында**—артиллериядән сирәк-сирәк атышу.

Һава начар булганлыктан авиациянең хәрәкәтләре чикләнгән характерда булды.

СОВЕТ САМОЛЕТЫ „ДС—3“ БЕРЛИНГӘ ОЧЫП КИЛДЕ

БЕРЛИН, 9 гыйнвар. (ТАСС). Бүген җирле вакыт белән 11 сәгат, 05 минутта яңа трасса буенча—Москва—Минск — Белосток—Кенигсберг — Данциг — Берлин трассасы буенча сынау очышы ясаучы совет самолеты „ДС—3“ Берлиндәге Рангсдорф аэродромына төште. Самолет экипажының составы: самолетның командиры иптәш Кириченко, пилотлар Хорпяков һәм Смирнов иптәшләр, борт-механик Монахов, борт-радист Глушаев иптәшләр.

Хәбәрчегез белән ясаган беседасында самолетның командиры иптәш Кириченко самолетның Москвадан Берлингә кадәр бөтен юлны уңышлы үткәнлеген әйтте. Бүген иртә белән 8 сәгат 55 минутта самолет Данциг аэродромыннан очып китте һәм расписание буенча төгәл 11 сәгат 05 минутта Берлингә килеп җитте. Машина төзек, юлда бер нинди ватылулар булмаган. Иртәгә, 11 сәгат 45 минутта самолет Москвага кире китәчәк.

Чиләбедәге авыл хуҗалыгы машиналары заводының 40 еллыгы

Шушы айда Чиләбедә авыл хуҗалыгы машиналары заводының (Колющенко исемендәге заводның) 40 еллыгы үткәреләчәк. Завод социалистик игенчелеккә бик күп санда трактор инвентары—сабаннар, тырмалар, культиваторлар бирә һәм хәзер агач утырту машиналары һ. в. эшләп чыгара башлаячак. (ТАСС).

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫНДА

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 9 гыйнвар. (Радио. ТАСС). Бозваткыч бозлар арасына кысылган хәлдә тик тора. Көньяк җиленең йогынтысы сизелә, һава кинәт җылынды. Бүген һаваның температурасы плюс 2 градус. 40—50 метр ераклыкны күрергә мөмкин. Вакыт-вакыт боз җиңелчә кыса. Кардан файдаланып, эчү өчен су запасы хәзерлибез. Бу эшкә бигрәк тә бүген, җылы көнне һәр кем теләп бара. Дөрес, елның бу вактында көн вакыт белән генә исәпләнә, чөнки тәүлек буе караңгы, шулай да бозваткычта көн һәм аның хокуклары бар.

И. Папанин.

БАШКАЛАНЫҢ СӘНГАТ МАСТЕРЛАРЫНА И. Д. ПАПАНИННЫҢ РАДИОГРАММАСЫ

9 нчы гыйнварга каршы төндә СССР Сәнгат Работниклары Үзәк Йортында батыр седовчыларның туганнары белән башкаланың сәнгат мастерларының очрашуы булды. Моннан „Г. Седов“ һәм „И. Сталин“ бозваткычларының экипажлары өчен радио аша зур тапшыру булды. СССР Сәнгат Работниклары Үзәк йортында концерт тәмам булганнан соң берничә сәгат үткәч, Арктика флоты флагманы „И. Сталин“ бозваткычы бортыннан түбәндәге радиограмма алынды:

„И. Сталин“ бозваткычында экспедициядә катнашучылар седовчыларның туганнарының башкаладагы сәнгат мастерлары белән очрашуларын тапшыруны зур игтибар белән тыңлыйлар. Безнең котыпчыларга игтибар күрсәтүегез өчен чын күңелдән рәхмәт кабул итегез. Артистларыбызның сәнгате монда, Арктика йөрәгенә тулы бәяле һәм саф булып килеп җитә. Чын күңелдән сәлам. Папанин“.

(ТАСС).

Совет—Болгария сәүдә договоры турында Болгария матбугаты

СОФИЯ, 9 гыйнвар. (ТАСС). Болгариянең җәмагат-политик һәм эшлекле даирәләре Совет—Болгария сәүдә сөйләшүләренең барышын зур игтибар һәм кызыксыну белән күзәттеләр. Сөйләшүләрнең уңышлы тәмам булуы турындагы хәбәрне монда зур канәгатләнү белән каршы алдылар. Болгария матбугаты СССР белән экономик элемтәләрнең Болгария халык хуҗалыгы өчен гаять зур әһәмияте барлыгы турында яза. Шушы көннәрдә генә „Слово“ газетасы: „Хәзерге вакытта, безнең тышкы сәүдәнең СССР белән сәүдә итүгә юл алуы бик уңышлы адым“ дип язган иде. Төрле хуҗалык-экономик оешмалар да договор төзүдән канәгатьләнгәнлекләрен белдерделәр. 7 нче гыйнварда чыккан барлык газеталар үзләренең беренче битләрен шушы мәсьәләгә багышланган хәбәрләргә бирделәр. Хәбәрләрнең текстларын газеталар зур заголовоклар белән һәм кара шрифтлар белән бирәләр: „Болгария—Совет договорына кул куелды“, „СССР белән Болгария арасында төзелгән договорны ике илнең дә җәмагатчелек фикере канәгатләнү белән каршылады“, „Божилов әфәнденең миссиясе уңышлы тәмам булды“. Кайбер газеталар зур аншлаглар белән чыктылар. „Черно море“, „Варненски новины“, „Народна борьба“ „Русенская поща“ һәм башка газеталар үзләренең хәбәрләрендә товар алмашуның нигезенә салынган иң күп уңайлык принципын күрсәтеп үтәләр һәм киләчәктә товар алмашуның күләме гаять зур булачакны күрсәтәләр. „Русенская поща“, „Варненски новины“ һәм башка газеталар иң якын дусларча атмосферада алып барылган сөйләшүләрнең уңышлы тәмам булуы Болгариядә дә, шулай ук Советлар Союзында да зур канәгатләнү белән каршы алынганлыкны аеруча күрсәтеп үтәләр.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

НАРКОМАТ ПАРТОЕШМАЛАРЫНЫҢ ЭШЛӘРЕН ЯХШЫРТЫРГА

ВКП(б) ның XVIII нче съезды наркоматлардагы башлангыч партоешмаларның бурычларын бик ачык итеп билгеләде. ВКП(б) ның XVIII нче съезды кабул иткән уставта болай диелә: „Партиянең наркоматлардагы оешмалары, совет учреждениеләре эшенең махсус шартлары аркасында контроль функцияләре белән файдалана алмаганлыктан, учреждениенең эшендәге кимчелекләр турында сигнал бирергә, наркоматның һәм аның аерым работникларының эшендәге җитешсезлекләрне күрсәтергә һәм үзләренең материалларын һәм фикерләрен ВКП(б) ҮК на һәм наркомат җитәкчеләренә җибәрергә тиешләр“.

ТАССР Наркомздравы һәм Наркомторгы янындагы партоешмалар съезд карарлары нигезендә үзләренең эшләрен бер кадәр яхшырттылар. Алар учреждениенең һәм аппаратта эшләүче аерым работникларның җитешсезлекләре турында партиянең югары оешмаларына һәм наркоматның җитәкчелегенә сигналлар бирә башладылар һәм булган кимчелекләрне бетерүдә шактый эш башкардылар.

Бу партоешмалар сайлау участкыларында агитация-масса эшләрен яхшы гына куйдылар. Наркомздрав партоешмасындагы 32 коммунистның 11 е һәм Наркомторг партоешмасындагы 28 коммунистның 12 се сайлау участкыларында агитатор булып эшләделәр. Алар хезмәт ияләре белән төрле темаларда 90 нан артык беседалар үткәрделәр һәм аларның җыелышларында докладлар ясадылар. Округ һәм участкы сайлау комиссияләренә членнар сайлап алу һәм шәһәр, район Советларына депутатлыкка кандидатлар күрсәтү эшенә актив рәвештә катнаштылар.

Ләкин болар эшнең башлангычы гына әле. Бу оешмаларның эшләрендә җидди кимчелекләр бар. Наркоматларның аппаратларында булган җитешсезлекләрне бетерү өчен көрәш һич тә канәгатьләнерлек түгел. Алар күп кенә хәлләрдә, наркоматның аерым бүлекләренең, секторларының һәм аерым работникларының эшендә булган җитешсезлекләр турында наркомат җитәкчеләренә сигналлар бирү белән генә чикләнгәннәр, ә ул җитешсезлекләрне вактында бетерү өчен тиешле чаралар күрмәгәннәр.

Кай вакытларда бу партоешмалар үзләренең функцияләренә кермәгән, ә наркомат җитәкчеләре башкарырга тиеш булган эшләр белән шөгыльләнгәннәр. Мәсәлән, Наркомздрав янындагы партоешма үзәк поликлиникада хуҗалык эшләренең торышын тикшергән, партия җыелышында милиция управлениесе начальнигы иптәш Дубовның докладын тыңлап, „Иптәш Дубовка шәһәрдә хулиганнарга каршы көрәшне көчәйтергә тәкдим итәргә...“ дип карар чыгарган.

Наркомздрав һәм Наркомторг партоешмалары үз наркоматларының аппаратларында эшләрне яхшырту, хезмәт дисциплинасын ныгыту буенча начар эшләгәннәр. Наркомздрав аппаратында эшләүче работниклар социалистик ярыш белән чолганып алынмаганнар. Башкыртстан Наркомздравы белән ике арада төзелгән социалистик ярыш договорының үтәлеше бер тапкыр да тикшерелмәгән. Бу наркоматларда хезмәт дисциплинасы йомшак. Наркомторгта 2 ай вакыт эчендә 12 кеше эшеннән алынган. Бу Наркоматларда эшләүче кайбер коммунистлар хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен көрәшү, масса-политик эшләрне җәеп җибәрүдә партоешмага булышу урнына, партиясез работникларны наркомат алдында торган бурычларны үтәү эшенә туплау урнына үзләре прогул ясыйлар.

Наркомздрав һәм Наркомторг партоешмаларында партия-масса эшләре һәм алдынгы кешеләрне партия сафларына тарту тиешле югарылыкка куелмаган. Шулар нәтиҗәсендә, партиягә кабул итү башланганнан бирле Наркомторг партия оешмасы ВКП(б) сафларына член итеп бары тик 3 кешене, кандидат итеп 2 кешене кабул иткән.

Бу оешмаларда коммунистларны политик тәрбияләү эше белән бик йомшак шөгыльләнәләр. Наркомздрав партоешмасында учетта торучы 32 коммунистның 11 е, Наркомторг партоешмасында учетта торучы 28 коммунистның 2 се „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү эшенә әлегә кадәр ныклап керешмәгән. Партиясез интеллигенция арасында партия тарихын өйрәнү эше тагын да начаррак тора. Мәсәлән, Наркомздрав аппаратында эшләүче 64 кешенең бары тик 13 е генә „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнә.

Бу партоешмалар наркомат янындагы комсомол оешмаларына тиешле игтибар биреп җиткермиләр. Наркомздрав янында комсомол оешмасының устав нигезендә төзелмәвен шул игтибарсызлык нәтиҗәсе дияргә кирәк. Мәсәлән, бу оешмада учетта торучы комсомолецларның күбесе Наркоматта эшләмиләр, ә Молотов һәм Сталин районнарында эшлиләр.

Наркомздрав һәм Наркомторг партоешмаларының эшләрендәге бу җитешсезлекләрнең төп сәбәбе ул оешмаларның алдан уйлап төзелгән план нигезендә эшләмәүләрендә, яки бөтенләй плансыз эшләүләрендә. Мәсәлән, Наркомздрав партоешмасы (секретаре иптәш Завьялов) 1939 нчы елның май, июнь, июль айларында бөтенләй плансыз эшләгән. Аннан соңгы айларда эш планы төзелсә дә, ул бюро утырышында да, партия җыелышында да тикшерелмәгән һәм шуның нәтиҗәсендә, бу оешмадагы коммунистлар планны үтәү эшенә тартылмаганнар, коллектив җитәкчелек принципы бозылган.

Бу партоешмаларның бюролары тарафыннан партиянең эчке демократиясен тупас рәвештә бозу фактлары бар. Мәсәлән, алар 1939 нчы ел буена үзләренең эшләре турында партия җыелышларында бер генә тапкыр да отчет ясамаганнар.

ВКП(б) ның Бауман райкомы тарафыннан Наркомздрав һәм Наркомторг партоешмаларына игтибар һич тә җитәрлек булмаган. Райком бу оешмаларга эштә көндәлек практик ярдәм күрсәтмәгән, аларның секретарьларына тегеге яки бу мәсьәләне ничек итеп хәл кылырга кирәклекне конкрет мисаллар үрнәгендә өйрәтмәгән. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел 14 нче ноябрь карары нигезендә интеллигенция арасында политик-масса эшләрен ничек куюы турында райком 1939 нчы елның апрелендә Наркомздрав партоешмасының эшен караган һәм карар чыгарган. Ләкин әлегә кадәр үз карарының үтәлешен тикшермәве белән һәм, бигрәк тә, бу карарның беренче пунктында Наркомздрав партоешмасының бурычын ялгыш билгеләп бик начар иткән.

Наркомздрав һәм Наркомторг партоешмаларының эшендә булган җитешсезлекләрне бетерү өчен ул оешмаларның җитәкчеләре һәм анда учетта торучы барлык коммунистлар, ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын һәм иптәш Ждановның докладын яхшы итеп үзләштерергә тиешләр. Бу оешмалар үзләренең эшләрен ВКП(б) уставының 61 нче параграфына туры китереп һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының Татнаркомпрос партия оешмасының эше турында 1939 нчы ел ноябрь аенда биргән күрсәтмәсе нигезендә яңача үзгәртеп корырга тиешләр.

Чудаков.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты инструкторы.

КОЛХОЗ АЛДЫНГЫЛАРЫ ПАРТИЯГӘ КЕРӘЛӘР

Буденный районы, „Гигант № 2“ колхозы янындагы башлангыч партоешма колхозның иң алдынгы кешеләре хисабына туктаусыз үсә. Партиябезнең тарихи XVIII нче съездыннан соң башлангыч оешма ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 5 кешене кабул итте. Яңа кабул ителүчеләр арасында колхозның алдынгы столяре иптәш Шәрифҗан Сөләйманов та бар.

Аңар хәзер 62 яш. Ул, революциягә кадәр башыннан күп кыенлыклар кичергән. Бер таңнан икенче таңга кадәр байларга эшләп, аларның терлекләрен көтеп яшьлек вакытларын батраклыкта үткәргән. Аның бер сынык икмәк күрмәгән көннәре күп булган. Бары тик революциядән соң гына бу кыенлыклар аның җилкәсеннән төштеләр.

Иптәш Сөләйманов колхоз оешкан елларда ук аңар член булып керде һәм колхозның столяре булып эшләп килә. Эшне намус белән үти, мебельләрне пөхтә итеп, җиренә җиткереп эшләве белән мактала һәм башкаларга үрнәк булып тора. Шуның белән бергә, Шәрифҗан картның тормышы тамрыннан үзгәрде, яхшырды һәм күңелләнде.

Иптәш Сөләйманов җәмагат эшенә дә актив катнаша. Ул колхозның правление члены итеп сайланды. Колхоз хуҗалыгын яхшырту буенча правлениегә көндәлек булышлык күрсәтә. Шуның белән бергә үзенең белем дәрәҗәсен күтәрүгә дә нык игтибар итә. Яңа алфавитны өйрәнә. Агротехника түгәрәгенә йөри. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н түгәрәккә йөреп өйрәнә. Занятиеләргә тәртипле рәвештә йөри һәм анда актив катнаша.

А. Яфизов.

ПАРТОЕШМА СЕКРЕТАРЬЛАРЫ ҺӘМ КАДРЛАР БҮЛЕГЕ МӨДИРЛӘРЕ КИҢӘШМӘСЕ

7 нче гыйнварда, ВКП(б) ның Бауман райкомының кадрлар бүлеге культура учреждениеләре янындагы партоешма секретарьларының һәм ул учреждениеләрнең кадрлар бүлеге работникларының киңәшмәсен үткәрде.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары һәм иптәш Сталинның күрсәтмәләре нигезендә кадрларны күтәрү һәм тәрбияләү эше турында райкомның кадрләр бүлеге мөдире иптәш Конкинның доклады тыңланды.

Партиянең тарихи съездыннан соң партия, хуҗалык, профсоюз, комсомол оешмалары кадрларны күтәрү һәм тәрбияләү эшендә кайбер уңышларга ирештеләр. 1939 нчы ел эчендә райондагы 108 оешмада җитәкче эшләргә 1.133 кеше күтәрелгән. Шуларның 226 сы хатын-кызлар.

Ләкин кайбер оешмаларның җитәкчеләре үзләренең бу өлкәдәге эшләрен ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын һәм иптәш Сталинның күрсәтмәләрен тулы үтәүне тәэмин итәрлек итеп оештырмаганнар әле. Мәсәлән, ГорОНО, Зур Драма театры,"Роснабторг һәм башка кайбер оешмаларда узган елны бер генә кеше дә, җитәкче эшләргә күтәрелмәгән.

Күп кенә оешмаларда кадрларны тәрбияләү һәм укыту эшләре аеруча начар тора. Кадрларның белемен күтәрү өчен билгеләнгән акча тулысынча файдаланылмый, кадрлар хәзерләүнең конкрет планы юк. Мәсәлән, Зур Драма театрында узган елны кадрлар хәзерләү өчен билгеләнгән 12 мең сум акчаның 4.000 сумы, Татполиграфта 21 мең сумның 12 мең сумы файдаланылмыйча калган. Кайбер оешмаларда хезмәт дисциплинасы начар. Кадрлар еш алмашына, Горзеленостройда узган елны 185 кеше, Горпожар охранада 102 кеше (шуларның 53 е прогул өчен) эшеннән алынган.

Кайбер хуҗалык оешмалары кадрлар хәзерләү эше белән начар шөгылләнәләр. Кинотрестның кадрлар бүлеге кино работниклары өчен курслар оештырырга җыена, ә нинди курслар һәм ни өчен ул курсларны оештыра, аны бүлек мөдире иптәш Краев үзе дә белми.

Киңәшмәдә чыгып сөйләүчеләр резерв белән эшләүнең канәгатьләнерлек булмавын күрсәтеп үттеләр. Үзәк китапханәдә, Сәнгать эшләре Идарәсендә, МОПР Өлкә Комитетында һәм Сугышчан Алласызлар Союзының өлкә советында резервның учеты да юк.

ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Суганов кайбер партоешма секретарьлары үзләренең политик һәм гомуми белем дәрәҗәләрен күтәрү өстендә җитәрлек эшләмәүләре турында сөйләде. Партоешма секретарьлары үзләренең урынбасарларын партия эшенә хәзерләүгә тиешле игтибар бирмиләр әле. Иптәш Суганов кадрларны тәрбияләү эше буенча алда торган конкрет бурчларны күрсәтеп үтте.

Ишкаев.

ВКП(б) ның Сталин райкомы пропагандисты иптәш А. Я. Гайнуллин трикотаж артеле эшче хатын-кызлары арасында партия тарихының „Кыскача курсы“н өйрәнүчеләргә групповой консультация бирә. И. Галиев фотосы.

ПАРТИЯ ХУҖАЛЫГЫНА ИГТИБАР ИТМИЛӘР

Кызыл Армия районы, „Восход“ колхозы янындагы башлангыч оешма секретаре иптәш Перцов партия хуҗалыгына җитәрлек игтибар итми. Бу оешмада коммунистларны учетка алу һәм аларны учеттан чыгару эше тиешенчә алып барылмый. Оешмадан күптән киткән коммунистлар биредә учетта булып күренәләр. Оешмада партия членлыгына кандидатлар 3 кеше исәпләнә, ә коммунистларны учетка алу кнәгәсендә 5 кеше күренә. Бу оешмада партҗыелыш протоколлары үз вакытында рәсмиләштерелмиләр һәм ВКП(б) райкомына җибәрелмиләр. Кайбер коммунистлар членлык взносларын түләгәнлекләре турында ведомостька 5 ай буенча кул куймаганнар.

„Большевик“ колхозы янындагы башлангыч патроешма секретаре иптәш Рәшитев башка оешмалардан килгән коммунистларны учетка алганда, учет кнәгәсенә аларның фамилияләрен генә яза. Кнәгәдәге башка графалар тутырылмыйлар.

ВКП(б) райкомының оештыру инструкторлык бүлеге бу фактларга игтибар итәргә, партия хуҗалыгындагы бу җитешсезлекләрне бетерүдә башлангыч партоешмаларга конкрет ярдәм күрсәтергә тиеш.

А. Закиров.

ДЕПУТАТЛАР ПАРТИЯ САФЛАРЫНА КЕРӘЛӘР

Әтнә районында җирле Советларның депутатлары Ленин—Сталин партиясе сафларына керәләр. Шушы көннәрдә район Советы депутаты Фатыйма Галиева, Күәм авылы Советы депутаты Абдул Кәримев, Олы Әтнә авыл Советы депутаты Зәкия Хәйруллина, Күлле Киме авыл Советы депутаты Бәйрәм Җәләлев, Күшәр авыл Советы депутаты Сара Гарәпшина иптәшләр ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул ителделәр.

Яш депутатлар җаваплы эшләргә күтәреләләр. Мәсәлән, Бәйрәм Җәлалев Күлле Киме авыл советы председателе итеп, Зәкия Хәйруллина Олы Әтнә авыл Советы председателенең урынбасары итеп сайландылар.

С. Мостафин.

ТАТАРСТАН ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ҖИРЛЕ СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫҢ ЙОМГАКЛАРЫ

Г. Динмөхәмәтов

ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының гүзәл яңа җиңүе белән тәмам булган сайлаулар совет кешеләренең әлегә кадәр күрелмәгән активлыклары обстановкасында үтте. Бу чын халык бәйрәме булды, бу совет җәмагатчелеге мораль - политик бердәмлегенең бөек демонстрациясе булды. Ирекле һәм бәхетле совет гражданнары сайлау урналарына бердәм уй һәм бердәм фикер белән бардылар. Аларны бер теләк—социализм иленең куәтен киләчәктә дә ныгыту, эшчеләрнең һәм крестьяннарнең дәүләт властын—Советларны ныгыту теләге берләштерде.

Коммунистлар партиясе һәм барлык хезмәт ияләренең юлбашчысы, дусты иптәш Сталин тарафыннан җитәкчелек ителә торган Советлар, дәүләт власты органы буларак, көчле революцион көрәш органы буларак, эшчеләрнең һәм крестьяннарнең социалистик дәүләте оештырылуның беренче көннәреннән үк Совет властының бөтен тарихы буена һәр вакытта да хезмәт ияләре интереслары ягында тордылар.

Гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү тәртибендә җирле Советларга үткәрелгән сайлаулар дәүләт властының барлык органнарын Сталин Конституциясе нигезендә үзгәртеп коруны төгәлләделәр, хезмәт ияләре депутатлары Советларын тагын да ныгыттылар, тагын да сугышчанрак һәм массовый иттеләр, аларны Советлар Союзының барлык гражданнары алдында тагын да авторитетлырак иттеләр. Советлар ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды тарафыннан куелган гаять зур бурычларны хәл итү өчен көрәшнең яңа средстволары белән коралландылар.

Сайлау алды кампаниясе ике ай барды. Безнең Татарстан республикасында сайлау комиссияләрендә генә дә 125.368 кеше эшләде. Шуларның 31 проценты хатын-кызлар, 89,3 проценты партиясезләр. 60 меңнән артык агитатор масса арасында большевистик агитация алып барды. Агитациядән читтә калган бер генә авыл да, бер генә йорт та, бер генә квартира да булмады.

Политик активлыкның зур күтәрелеше хуҗалык өлкәсендә зур уңышларга ирешүне тәэмин итте. Совет халкы сайлаулар көненә промышленность, транспорт, коллективлашкан авыл хуҗалыгы өлкәсендә зур, яңа уңышлар белән килү өчен көрәште. Заводларда һәм фабрикаларда стахановчылык хәрәкәтенең яңа дулкыны күтәрелде. Эшчеләр сайлаулар көне якынлашуны массовой производство рекордлары белән, берничә станокта эшләүгә күчү белән билгеләделәр. Күп кенә заводлар (жиркомбинат, язу машиналары заводы һ. б.) еллык программаны срогыннан элек үтәделәр.

Авыл хезмәт ияләре дә сайлаулар кампаниясен производство күтәрелеше белән истә калдырдылар. Нөркәй МТС ы трактор паркына ремонт ясауны 24 нче декабрьгә тәмам итү турында йөкләмә алган иде һәм ул бу йөкләмәсен үтәде. Нөркәй МТС ы чакыруына башка МТС лар да кушылдылар. Колхозчылар 1940 нчы елда һәр гектардан кимендә йөз пот уңыш алу өчен большевистик көрәш башладылар.

Сталин Конституциясенең барлык җимешләре белән файдаланучы, большевиклар партиясе тарафыннан, социализм төзелешенең барлык участкыларындагы данлыклы эшләре белән рухланган совет халкы үзенең тирән патриотизмын, Ватанга мәхәббәтен, аның киләчәктә дә чәчәк атуы турында өзлексез кайгыртучанлыгын күрсәтте. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына кандидатлар күрсәтүгә багышланган барлык сайлау алды җыелышлары да шушы теләк белән, шушы кайгыртучанлык белән тулы булды.

Сайлау алды җыелышлары сайлау кампаниясенең хәл иткеч этапы булды. Бу җыелышларда коммунистлар һәм партиясезләр бергә Советларга үзләренең вәкилләрен күрсәттеләр һәм аларны тикшерделәр. Алар булачак депутатларның сыйфатларына нык һәм эшлекле рәвештә, ашыкмыйча бәя бирделәр, кешеләрнең халык эшенә бирелгәнлекләренә хәзер торуларын тикшерделәр. Монда—сайлау алды җыелышларында—коммунистларның һәм партиясезләрнең союзы тагын да ныгыды, барлык оешмалар һәм хезмәт ияләренең җәмгыятләре тарафыннан кандидатлар күрсәтүдә бөек хокук тормышка ашырылды.

Безнең социалистик дәүләтебездә эксплуататор сыйныфларның яшәве өчен экономик шартлар бетерелде. Ләкин әле эшчеләр сыйнфы белән крестьяннәр арасындагы аерма бетмәде, акыл белән физик хезмәт арасындагы аерма тулысынча бетеп җиткәне юк, әле безнең илебез капиталистик чолганышта яшәүдә дәвам итә, әле безнең социалистик дәүләтебезгә капиталистик державаларның һөҗүм итмәячәкләренә гарантиябез юк. Димәк, безгә эшчеләр сыйнфы диктатурасының какшамас булуын көн саен ныгытырга кирәк, Советлар, социалистик җәмгыятнең дәүләт формасы буларак, үзләренең тарихи бурычлары биеклегендә калырга тиешләр.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогында кандидатларны сайлап алу һәм күрсәтү нак менә шушы теләкне — Советларны киләчәктә дә ныгыту теләген—күз алдында тотты. Менә шуның өчен сайлау алды җыелышларында кандидатлар шундый нык һәм җидди рәвештә тикшерелделәр. Һәрбер кешегә дә халык депутаты булу бирелмәгән. Үз халкының яхшы сыйфатларын булдырган, халыкка һәм Ленин—Сталин партиясенә ахрынача бирелгән кеше генә сайлаучыларның үзен яклаячагына исәп тота ала.

24 нче декабрь көне, Верховный Советларга сайлаулар көннәре шикелле үк, коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатлары сайлаучылар тарафыннан зур авторитет белән файдаланганлыкны күрсәтте. Халык сайлау урналарына барганда, ул тавыш бирә торган кешенең үзенең бөек постында намус белән эшләячәгенә, сайлаучылар теләген тулысынча үтәячәгенә ышанып барды. Халык сайлау урналарына үзенең тавышын Ватанга, партиябезгә, бөек Сталинга бирү өчен барды.

24 нче декабрь көне хезмәт ияләренең киң массасының политик аңлылыгы гаять зур үскәнлекне күрсәтте. Миллионнарча совет кешеләре тавыш бирү актында үзләренең гражданлык бурычларының, коммунизм төзелешендә актив катнашучыларның мактаулы бурычларының үтәлүен күрделәр.

Татарстанда 1934 нче елда шәһәр, район һәм поселкы Советларына сайлаулар вактында, тавыш бирергә хокуклары булган гражданнарның, тавыш бирүдә 84,7 проценты катнашты, авыл советларын сайлауларда 75,2 проценты катнашты. Бу саннар ул вакытта гаять зур булып саналдылар. Хәзер бу саннар безнең тарафтан бик күп артка калдырылды. 24 нче декабрьдә хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына булган сайлауларда шәһәрдә дә һәм авылда да сайлаучыларның барсы да дип әйтерлек катнашты: Татарстан республикасы гражданнарының 98,8 проценты сайлауларда катнашты, күп кенә авылларда, күп кенә сайлау участкыларында барлык сайлаучылар тавыш бирүдә катнашты. Кузнечиха, Азнакай, Актаныш, Мөслим, Әлмәт, Ютазы, Тәмте, Сарман, Заинский районнарында сайлаулар аеруча оешкан һәм бердәм рәвештә үтте. Бу районнарда 99 проценттан артык сайлаучы тавыш бирде.

Барлык урыннарда да дип әйтерлек халык сайлау участкыларына тавыш бирү башланганчы җыелды. Һәр кем коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидаты исме язылган бюллетенне урнага беренче булып салырга теләде. Беренче Май районындагы „Красный Октябрь“ колхозында көндезге 12 сәгаткә барлык сайлаучылар да тавыш биреп бетерде. Югары Акташ сайлау участкысында көндезге 3 сәгаткә 1.009 кешенең барсы да тавыш биреп бетерде. Биектау районындагы барлык сайлау участкыларында да тавыш бирү, нигездә, көндезге 4 сәгаткә тәмам булды. Совет кешеләренең биек активлыгын күрсәтә торган мондый мисальләр массовый характерда булды.

Татарстан хезмәт ияләре иң яхшы кешеләрне, Ленин—Сталин партиясе эшенә, социализм эшенә бирелгән кешеләрне үзләренең тулы хокуклы вәкилләре итеп җирле Советларга җибәрделәр.

Депутатларның составы, соңгы елларда совет җәмгыяте структурасында килеп чыккан гаять зур үзгәрешләрне көзге кебек ачык күрсәтә. Бездә кешенең кешене эксплуатацияләве бетерелде. Кешеләрнең талантларын һәм сәләтләрен үстерү өчен яхшы шартлар тудырылды. Капитализмның алдау законнары обстановкасында

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШКА ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТӘРГӘ КИРӘК

Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының чакыруын Шөгер районындагы колхоз председательләренең, бригадирларының һәм стахановчыларның район киңәшмәсе зур бердәмлек белән кабул итеп, районның барлык колхозчыларын, колхозчы хатын-кызларын, авыл хуҗалыгы белгечләрен бөртекле культураның һәр гектарыннан йөз пот иген уңышы алу өчен көрәшергә, моның өчен социалистик ярышны киң җәелдерергә чакырган иде.

Бу бурыч Шөгер районы шартларында үтәлерлекме? Әйе, үтәлерлек һәм бик реаль. Моның шулай икәнлеген районның алдынгы колхозларының, бригадаларының бай тәҗрибәләре тулысынча раслый. Һава шартларының соңгы ике ел эчендә беркадәр начар булуына да карамастан, „Яш Көч" колхозы бөртекле культураларның һәр гектарыннан соңгы өч елда 88 әр пот, „Техника" колхозы 75 әр пот уңыш алганнар. 1939 нчы елда „Яш Көч" колхозының иптәш Кәримов җитәкчелегендәге звеносы 27 гектар бодайның һәр гектарыннан уртача 96 пот, „Первое Мая" колхозының иптәш Мурзина җитәкчелегендәге звеносы 40 гектар бодайның һәр гектарыннан уртача 84 пот, „Шушма" колхозының иптәш Ваһапова җитәкчелегендәге звеносы гектарыннан уртача 122 потлары уңышы алганнар. Алар бу уңышларга хезмәтне дөрес оештыру, социалистик ярышны киң җәелдерү, агротехника чараларын вактында һәм төгәл итеп үткәрү нәтиҗәсендә ирешкәннәр.

Калинин районы алдынгыларының һәм Шөгер районы күләмендәге киңәшмәнең 1940 нчы елда югары уңыш алу буенча социалистик ярыш оештыру турында мөраҗәгатьләре районның барлык колхозларында диярлек гомуми җыелышларда тикшерелгән, ярышка кушылу турында күп кенә карарлар чыгарылган. Ләкин социалистик ярышны бригадаларда, звеноларда, аерым колхозчылар арасында оештыру эше күпчелек колхозларда бөтенләй башланмаган. Партиянең күп кенә колхозлардагы башлангыч оешмалары бу эшне үз агымына куйганнар. Район җир бүлеге мөдире иптәш Сафуанов, МТС директорлары Николаев һәм Газизов иптәшләр колхозларда социалистик ярышны оештыру, кышкы агротехника чараларын үткәрүдә җитәкчелек итүдән бөтенләй диярлек читләшкәннәр. Шуңа күрә алар колхозларда язгы чәчүгә хәзерлекнең торышын ачык белмиләр. Районда 14 агроном бар. Алар йөзпотчылар ярышын оештыруда партия, совет оешмаларына, колхоз җитәкчеләренә якыннан ярдәм итәргә, бу хәрәкәтне оештырырга тиешләр иде. Ләкин аларның күпчелеге, бигрәк тә „Үзәк" МТС ы һәм җир бүлеге агрономнары төрле сылтаулар астында гыйнвар аена кадәр колхозларда бик сирәк булганнар.

Районда 1940 нчы елда югары иген уңышы өчен көрәшнең хәзергә әле йомшак оештырылган булуын бөтен ачыклыгы белән күрсәтергә кирәк. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау, кар тоту, тирес чыгару, фекаль, көл җыю эшләре, орлык тазарту, сбруйлар хәзерләү эшләренең барышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Мисальгә Иске Иштирәк авыл советына караган „Шушма" колхозын (председателе иптәш Гәрәев), „Ярыш" колхозын (председателе иптәш Җәләлиев) китерергә була. Бу колхозларда Калинин районы алдынгыларының мөраҗәгатен гомуми җыелышта тикшергәннәр дә, шуның белән тынычланып калганнар. Бригадалар арасында конкрет йөкләмәләр алып, ярыш договорлары төзелмәгән. Кар тоту планы 50—60 процент кына үтәлгән. Аның да сыйфаты түбән. Авыл хуҗалыгы машиналарының яртысына гына ремонт ясалган. Басуга тирес чыгару эше тагын да начаррак тора. Фекаль җыю бөтенләй башланмаган диярлек. Орлык тазарту эшләренең темпы да бик түбән. Бу колхозларда партиянең башлангыч оешмасы бар (секретаре иптәш Шиһапов). Ләкин ул колхозларда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре белән тиешенчә шөгыльләнми. Дөрес, партия җыелышларында карарлар чыгарыла, ә аларның үтәлешен тикшерү оештырылмый. Мондый фактларны күп кенә башка колхозлар турында да күрсәтергә мөмкин.

Районда язгы чәчүгә хәзерлекне уңышлы оештырган колхозлар да юк түгел. Шул ук Иске Иштирәк авыл советына караган Куйбышев исемендәге колхозны алыйк. Монда басуга тирес чыгару эше планлы рәвештә бара, машиналарга ремонт ясау төгәлләнеп килә. Кар тоту планы тулысынча үтәлү алдында тора. Орлыкларны тазарту нигездә төгәлләнгән. Бу колхоз, язгы чәчүгә үрнәкле итеп хәзерлекне якын көннәрдә һич шиксез, тәэмин итәчәк.

Район җир бүлеге һәм МТС җитәкчеләре шундый колхозларның тәҗрибәләрен башкаларга күчерү эше белән шөгыльләнергә, социалистик ярышка конкрет җитәкчелекне көчәйтергә тиешләр.

И. Узбеков.

Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә хәзерлек

Күргәзмәгә үрнәк рәвештә хәзерләник

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе илебездә социалистик авыл хуҗалыгының бөек җиңүләрен күрсәтүче гүзәл демонстрация булып тора. Күргәзмә авыл хуҗалыгы алдынгыларының, стахановчыларның бай тәҗрибәләрен популярлаштеру мәктәбе булып хезмәт итә.

1939 нчы елда күргәзмәнең 3 айга якын эшләве чорында аны 3 миллионнан артык кеше карады. Орденлы Татарстан республикасы павильоны да күргәзмәдә күрнекле урыннарның берсен алды. Анда республикабызның алдынгыларыннан 3.060 экспонент катнашты. Павильонда Советлар Союзының төрле почмакларыннан килгән 1,5 миллионнан артык экскурсант булды.

1939 нчы елда күргәзмәгә хәзерлек эшендә татарстан АССР да кайбер җитешсезлекләр булды. Терлекчелек совхозлары, колхозларның терлекчелек фермалары һәм аларның алдынгылары күргәзмәгә җитәрлек санда катнашмадылар, фәнни работникларның тәҗрибәләрен күрсәтү канәгатьләнерлек булмады, күргәзмәгә китерелгән натураль экспонатлар аз булды һәм экспонатларның сыйфаты шактый түбән булды.

Балтач районыннан кырчылык буенча, Әлки районыннан терлекчелек буенча күргәзмәгә бер генә экспонент та катнашмады. Югары Ослан, Кама Тамагы, Кызыл Юл, Чепья районнарыннан бары 1—5 экспонент катнашты. Бу хәл, күрсәтелгән районнарда күргәзмәгә катнашу хокукын алырлык күрсәткечләре булган колхозлар, терлекчелек фермалары, авыл хуҗалыгы алдынгылары булмау дигән сүз түгел, алар бар. Ләкин бу районнарның җитәкчеләре күргәзмәгә хәзерлек эшенә әһәмият бирмәделәр. Нәтиҗәдә, үз районнарындагы күп кенә авыл хуҗалыгы алдынгыларын 1939 нчы елда күргәзмәгә катнашудан мәхрүм иттеләр.

Күргәзмәгә хәзерлек эшендәге үткән елгы бу җитешсезлекләр быел һич тә кабатланмаска тиеш. Моның өчен вактында бөтен чараларны күрергә кирәк. 1940 нчы елда күргәзмәгә катнашучы экспонентлар санын үткән елга караганда бермә-бер арттырырга кирәк. Моңа ирешү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Ләкин бу мөмкинлекләрдән файдалану һәм күргәзмәгә хәзерлек эше республикабызда һич тә канәгатьләнерлек түгел әле. Татарстан Җир эшләре Халык Комиссариатына әле бүгенге көнгә бары 1.161 гариза килгән. 11 районнан (Аксубай, Әлки, Апас, Этнә, Бондюг, Биләр, Дөбъяз, Заинский һ. б. районнардан) бер генә гариза да кермәгән. Шулай ук 11 районнан (Олы Тархан, Алабуга, Кама Тамагы, Кызыл Йолдыз һ.б.) кырчылык буенча, 20 районнан (Әгерҗе, Азнакай, Ворошилов, Чүпрәле, Красный Бор, Куйбышев, Мамадыш, Минзәлә һ. б.) терлекчелек буенча бер генә гариза да кергәне юк. Республикабыздагы совхозларның да күпчелеге күргәзмәгә хәзерлек эшеннән бөтенләй читтә калып киләләр.

Эшнең болай начар баруы, барыннан да элек, Татарстан Наркомземының, совхозтрестның, шәһәр тирәсе хуҗалыклары трестының, спирттрестның һәм мясотрестның күргәзмәгә хәзерлек эшенә тиешенчә җитәкчелек итмәүләрендә. Шулай ук күп кенә районнарның партия, совет һәм хуҗалык оешмалары җитәкчеләре бу эшне үз агымына куйганнар. Алар әле һаман да үткән елдагы җитешсезлекләрнең кабатлануына юл куялар. 1940 нчы елда күргәзмәгә катнашырлык күрсәткечләргә ия булучыларның гариза бирүләрен оештырмыйлар һәм бу эштә масса арасында аңлату эшләрен җитәрлек алып бармыйлар.

Бу җитешсезлекләрне һич кичекмәстән бетерергә, Сарман, Актаныш районнары кебек күргәзмәгә яхшы хәзерләнүче районнар үрнәгендә бу эшне киң рәвештә җәеп җибәрергә кирәк. Бу районнарның беренчесеннән 1940 нчы елда күргәзмәгә катнашуны сорап 193 гариза, икенчесеннән 170 гариза кергән иде. Эшне яхшы итеп оештырганда республикабызның башка районнарыннан да күп санда экспонентлар табарга мөмкин. Моның өчен һич кичекмәстән масса арасында аңлату эшләрен киң күләмдә җәеп җибәрергә, күргәзмәгә катнашырлык күрсәткечләрне яулап алган алдынгыларны табарга, документларны рәсмиләштерүдә аларга ярдәм итәргә кирәк.

Натураль экспонатларның сакланышын һәр вакыт тикшереп торырга һәм аларны вактында Москвага җибәрергә кирәк. Бу эшләр дәүләт тарафыннан куелган срокта, ягни 1940 нчы елның 15 нче февраленә тәмамланырга тиеш.

Урыннардагы партия, совет һәм хуҗалык оешмалары 1940 нчы елда авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашучыларның санын тагын да үстерү өчен большевистик җитәкчелекне тәэмин итәргә тиешләр.

А. Корбанов.



РӘСЕМДӘ: Чистай шәһәрендәге суднолар ремонтлау заводының атаклы стахановчысы токарь, хезмәт ияләре депутатларының район советы депутаты иптәш Гибалин эш вактында.

Колчин фотосы.

ИРЕШЕЛГӘН УҢЫШЛАРНЫ НЫГЫТАБЫЗ

Кун-галантерея фабрикасы коллективы үткән ел планын срогыннан элек үтәде. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә, продукциянең сыйфатын яхшыртуда, товарның үзенә төшү бәясен киметүдә шактый зур уңышларга ирештек. Хезмәт хакы фондына 11 ай эчендә 34 мең 660 сум экономия ясалды. Хезмәт җитештерүчәнлеге 17,7 процент күтәрелде.

Без бу уңышларга Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен киң җәелдерү аркасында ирештек. Бу вакыт эчендә бездә стахановчылар һәм ударниклар саны шактый артты. Мәсәлән, 1939 нчы елның 1 нче гыйнварына 89 стахановчы булса, 1940 нчы елның 1 нче гыйнварына стахановчыларның саны 116 кешегә җитте.

Фабриканың алдынгы стахановчыларыннан Казанцев, Фролова, Исламова, Глухов, Галиуллина, Газизова, Бәһаветтинова иптәшләр норманы һәр вакыт 150—250 процент итеп үтиләр. Бик күп стахановчылар җитәкче эшләргә: мастер, бригадир, цех начальниклары булып күтәрелделәр. Стахановчылардан Кудряков, Галәветтинев, Дубровский иптәшләр цех начальнигы, Хисаметтинев, Матвеев һәм Байбурина иптәшләр мастер итеп күтәрелделәр.

Без 1940 нчы елда тагын да яхшырак эшләү өчен көрәшәбез. Еллык планны срогыннан элек үтәп хезмәт җитештерүчәнлеген үткән елга караганда 15 процент күтәрүне йөкләмә итеп алдык. Алган йөкләмәләрне уңышлы үтәүне тәэмин итү өчен конкрет чаралар билгеләдек.

Салканов.

Төзелеш эшчеләре ярышы

Зеленодольск районы, Паратск поселкысындагы төзелеш эшчеләре коллективы Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярышка кушылып, үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алганнар иде. Алар ярыш йөкләмәләрен тулы үтәү өчен ныклы көрәш алып баралар. Балалар бакчасы өчен бина, 35 квартиралы торак йорты срогыннан элек төзелде һәм эксплуатациягә бирелде. Болардан тыш тагын 20 шәр квартиралы 3 йорт өлгертелде.

Җир казучылар бригадасында (бригадиры иптәш Панина) 18 хатын-кыз эшли. Алар үзара ярышалар. Ярышып эшләү бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Аның бригадасы соңгы айларда планны системалы рәвештә 200—280 процент итеп үти. Слесарьлар бригадасы (бригадиры иптәш Кеселев) айлык планны 180—200 процент итеп үти. Бу бригаданың алдынгы стахановчысы иптәш Мәҗитев Ярулла айлык планны уртача 300—400 процент итеп үтәүгә ирешә. Штукатурчылар, ташчылар бригадалары да планны 180 процент итеп үтиләр.

Ш. Шәриф.

Ике район ярышы

1939 нчы елда финанс планын яхшы күрсәткечләр белән үтәп чыгу өчен Заинск һәм Ширәмәт район финанс бүлекләре үзара социалистик ярыш договорлары төзегәннәр иде. Бу ярышта алдынгылыкны Заинск район финанс бүлеге алды. Заинск район финанс бүлеге работниклары һәм финанс активистлары социалистик ярыш договоры буенча үз өсләренә алган йөкләмәләрен намус белән үтәделәр. Район ирекле һәм мәҗбүри түләүләр буенча планны арттырып үтәп, республика күләмендә алдынгылыкны яулап алды.

Районда барлыгы 32 авыл советы бар. Бу авыл советларының налог агентлары һәм финанс активистлары барсы да үзара ярышып эшлиләр. Договорларның үтәлеше системалы рәвештә тикшерелә. Хәзер районда финанс активистларының саны 800 кешегә җитте. Шулардан 162 кеше финанс отличнигы һәм ударниклар.

Менә Карманай авыл советы председателе иптәш Файрушин. Аның җитәкчелегендәге Карманай авыл советы финанс планын ай саен арттырып үти.

Карманай авыл советы районда иң алдынгы авыл советларыннан берсе булган Бигеш авыл советы белән ярыша. Карманай авыл советы председателе Файрушин, Бигеш авыл советы председателе Авзалов иптәшләр үзләренең тырышлыклары һәм эш сөючәнлекләре белән колхозчылар арасында зур авторитет казандылар. Шуның өчен дә колхозчылар бу иптәшләрне Заинск район советына депутат итеп сайладылар.

Ләкин Ширәмәт район финанс бүлеге работниклары ярышып эшләүгә формаль рәвештә генә караганнар. Йөкләмәләрнең үтәлеше тикшерелмәгәннәр. Аларны үтәүгә киң масса тартылмаган. Авыл советларының күбесе ярышып эшләми. Күп кенә финанс секцияләре һәм комсодлар финанс туплау эшеннән читтә торалар. Район финанс бүлеге работниклары һәм налог агентлары үзләренең эшләре белән түбәнге финанс активистларына үрнәк булып тора алмыйлар. Шунлыктан Ширәмәт районы финанс туплау буенча республикада иң артта баручы районнарның берсе булып тора.

Шәрипов.

КОЛХОЗЛАРДА СТАХАНОВЧЫЛАР МӘКТӘПЛӘРЕ

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының югары иген уңышы алу буенча тәҗрибәләрен тирәнтен өйрәнү һәм аларның тәҗрибәләрен практикада киң куллану өчен ВКП(б) ның Тәкәнеш район комитеты район җир бүлеге белән берлектә „Новая Жизнь", „Вторая Пятилетка", „Виль-Султан", „Кызыл Йолдыз", „26 Баку комиссарлары" һәм башкаларда (барлыгы 8 колхозда) стахановчылар мәктәпләре оештырды. Хәзерге көндә бу мәктәпләрдә районның авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан, ударник һәм стахановчыларыннан 300 кеше укый. Мәктәпләр уку китаплары белән, күргәзмә материаллар һәм квалификацияле укытучылар белән тәэмин ителгән. (ТатТАСС).

ЯРЫШЫП ЭШЛӘҮ НӘТИҖӘСЕ

Кызыл Юл районы, Татарстанның 15 еллыгы исемендәге колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре уңышлы бара. Бу колхоз язгы чәчүгә хәзерлекне уңышлы төгәлләү өчен Вахитов исемендәге колхозны социалистик ярышка чакырды. Бригадалар һәм аерым колхозчылар арасында ярыш договорлары төзелде.

Колхозда язгы чәчү өчен кирәкле орлыклар җитәрлек кадәр хәзерләнде һәм чистартылды. Лабораториядә тикшергәннән соң орлыкларның сыйфаты яхшы дип табылды.

Колхозчылар ярыш договорын төгәл үтәү өчен нык көрәшәләр. Машиналарга ремонт ясауда тимерчеләрдән Чернов һәм Әхметханов иптәшләр норманы арттырып үтәп баралар. Сафин һәм Дәүләтшин иптәшләр басуга тирес чыгаруда көнлек норманы системалы рәвештә 112 процент үтиләр.

Исхак Хөсәенев.

тәрбияләнгән иске интеллигенциягә алмашка, үзенең көчен һәм белемен эшчеләргә, крестьяннәргә бирүче яңа интеллигенция килде. Партиябезнең эшчеләр сыйныфының культура дәрәҗәләрен инженер-техник хезмәте работниклары дәрәҗәсенә күтәрергә дигән лозунгысы уңышлы рәвештә тормышка аша.

Җирле Советларның депутатлары составы совет халкының бу сыйфат үзгәрешен, аның культура һәм материаль көчләренең үсешен бөтен тулылыгы һәм ачыклыгы белән чагылдыра. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларында социалистик хезмәтнең барлык профессияләре һәм шуның белән бергә үз эшенең иң гүзәл мастерлары бар. Монда күренекле педагог математика профессоры Григорьев, монда „Урожай" колхозының атаклы терлекчесе орденлы Никитин, хезмәттә стахановчы методларны кыюлык белән кертүче токарь Гибалин, талантлы шагыйрь орденлы Шәйхи Маннур, агроном-селекционер Байчурова, республикабызның халык артисткасы Асия Измайлова, танылган тукучы Малова, Хасан күле сугышларында геройларча катнашкан Ганцаревич, Габитов, өлкән машинист—орденлы Крылов, тракторчы Вәлиәхметова иптәшләр. Татарстанда җирле Советларга барлыгы 26.702 депутат сайланды. Алар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы депутатлары.

Алар арасында—өчтән бер өлеше диярлек—8.634 хатын-кыз. Бу, совет хатын-кызының социализм төзүдә тигез хокуклы икәнлеген, ул үзенә Сталин Конституциясе белән бирелгән хокукны эштә тормышка ашыра икәнлекне тагын бер кат ачык күрсәтә.

Депутатлар арасында ВКП(б) членнары һәм кандидатлары 7.171 кеше. Бу, хезмәт ияләренең киң массасы тарафыннан үзләренең авангардына—бөек Ленин—Сталин партиясенә булган гаять зур ышанычны күрсәтә. Безнең халык бөтен дөнья күләмендәге тарихи җиңүләре белән, үзенең ирекле, бәхетле, шатлыклы тормышы белән большевиклар партиясенә, юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталинга бурычлы.

Депутатлар арасында партиясезләрдән 19.531 кеше. Бу, партиябезнең күп санлы партиясез большевиклар, Ватаныбызның ялкынлы патриотлары активы белән чолганып алынуы турында сөйли. Алар өчен үзләренең көчләрен халык файдасына, коммунизм эшенә бирүдән дә мактаулы эш юк.

Депутатлар арасындагы 517 кешенең югары белеме, 2.981 кешенең урта белеме бар. Авыл Советларына гына да агрономнардан, зоотехниклардан, врачлардан һәм интеллигентлар хезмәтенең башка работникларыннан тыш 1.049 укытучы сайланды.

Бу, җирле Советлар алдына куелган тарихи бурычларны уңышлы рәвештә үтәрлек, сәләтле гаять зур көч. Яңа сайланган Советлар эшкә керештеләр инде. Советларның беренче сессияләре бөтен урыннарда да тәмам булды. Алар бик әһәмиятле оештыру мәсьәләләрен хәл иттеләр. Башкарма комитетлар төзелде, даими комиссияләр оештырылды, башкарма комитетларының бүлекләре комплектлаштырылды. Сессияләр гаять бердәм һәм эшлекле обстановкада үтте. Шулай итеп, депутатларыбызның зур, җаваплы дәүләт эшенә башлангыч салынды.

Татарстан АССР Конституциясенең 51 нче статьясе хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларының бурычларын ачык билгели. Алар үзләренең территорияләрендә культура-политик һәм хуҗалык төзелешләренә җитәкчелек итәләр, җирле бюджетны билгелиләр, үзләренә буйсынган идарә органнары эшенә җитәкчелек итәләр, дәүләт тәртибен саклауны тәэмин итәләр, илебезнең оборона сәләтен ныгытуга ярдәм итәләр, законнарның тормышка дөрес ашырылуын һәм гражданнарның хокукларын саклауны тәэмин итәләр.

Бу бурычларны үтәү өчен җирле Советларның депутатларына киң хокуклар бирелгән. Халык аларны сайлады, шуның белән, хезмәт ияләре интереслары өчен намус белән һәм үз-үзләрен аямыйча хезмәт итәрләр дип, депутатларга үзенең ышанычын күрсәтте. Моны һәрбер депутат бер генә минутка да исеннән чыгармаска тиеш.

Депутатның уңышлы эшенең иң әһәмиятле шартларының берсе—аның сайлаучылар белән, масса белән нык элемтәдә булуы. Ул һәрбер чараны, һәрбер эшне активка нык таянган хәлдә үткәрергә тиеш. Эшкә активны киң рәвештә тартмый торып, хезмәт ияләренең үзләренең ярдәменнән тыш депутатның уңышлы эше булуы мөмкин түгел.

Сайлау кампаниясе барышында политик һәм җәмагат эшенә ун меңнәрчә эшчеләр, колхозчылар, интеллигентлар кушылды. Бу кадрлар — агитаторлар, пропагандистлар, доверенныйлар, сайлау комиссияләре членнары—партиянең һәм Советларның алтын фонды. Бу кадрларны саклап калырга, аларны тагын да активлаштырырга, аларны яңа сайланган советларның эшләрен юлга салу һәм оешу ягыннан ныгыту буенча практик иҗади эшкә тартырга—депутатның беренче бурычы әнә шул.

Татарстан АССР дагы җирле Советларның составында 18.050 кеше дәүләт властьы органнарына беренче тапкыр сайланган. Бигрәк тә авыл советлары составы яңарды: 22.261 депутаттан 14.666 кеше беренче тапкыр сайланды. Болар үз эшләренә иксез-чиксез бирелгәннәр, ләкин аларның күбесенең совет эшендәге күнегүе, тәҗрибәсе җитми. Партия оешмаларының бурычлары—аларга һәр яклап булышлык итү, аларны идея ягыннан коралландыру.

Советлар алдында торган бурычлар бөек һәм мактаулы. Бары тик депутатлар үзләренең политик белем дәрәҗәләрен күтәрү өстендә көндәлек эш алып барганда гына, большевизмны нык үзләштергәндә генә, сайлаучылар белән тыгыз элемтә тотканда гына, хезмәт ияләренең сораулары на сизгер һәм әһәмиятле рәвештә колак салганда гына һәм аларны тулысынча канәгатьләндергәндә генә бу бурычлар уңышлы хәл ителәчәк. Татарстан АССР дагы җирле Советларның коммунистик төзелешкә уңышлы һәм файдалы эшләячәкләренә, эшчеләрнең һәм крестьяннарнең социалистик дәүләте көчләрен арттырачакларына һичбер шик юк.

АРТТА КАЛУЧЫЛЫКНЫ БЕТЕРЕРГӘ

Теләче районы, Күкчә авыл советы финанс туплау буенча 1939 нчы елның IV нче квартал планын 10 нчы декабрьгә тулысынча, ә еллык планны 124 процент итеп үтәде. Авыл советы финанс планын үтәүгә бәйле булган барлык мәсьәләләрне активистлар белән бергәләп хәл итә. Финанс планының үтәлеше турындагы мәсьәләләр буенча авыл советында әледән-әле киңәшмәләр була, анда налог агентларының информацияләре тыңлана.

Финанс активистларының һәр берсе аерым участкыда эшли. Алар йөкләмәләрне үз вактында үтәүнең политик әһәмияте турында колхозчылар арасында аңлату эшләре алып баралар.

Финанс планын үтәүдә яхшы эшләве өчен Күкчә авыл советы район финанс бүлегенең күчмә кызыл байрагы белән бүләкләнде.

Ләкин районда финанс планын үз вактында үтәмәүче авыл советлары да бар әле. Мәсәлән, Тәмте, Казаклар һәм Алан авыл советлары финанс планын үтәүдә ай саен койрыкта сөйрәлеп киләләр. Район финанс бүлеге алдынгы авыл Советларының эш тәҗрибәләрен артта калучы авыл советларына күчерү эше белән җитәрлек кадәр шөгыльләнми.

Әхмәтҗанов.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

БРЮССЕЛЬ, 9 гыйнвар. „Журналь" газетасының 8 нче гыйнварда бирелгән хәрби күзәтүендә болай диелә: „Бераз вакыттан бирле диңгез көчләренең активлыгы шактый кимеде. Германиянең су асты көймәләре һөҗүмнәрен туктаттылар. Авиациянең хәрәкәте әйтерлек булмады.

Коры җирдә, фронтлар арасындагы полосада ике яктан да күп санлы патрульләр хәрәкәт итте. Җирле әһәмиятле берничә бәрелеш булды. Бу бәрелешүләр вактында французлар берничә кешене пленгә алдылар.

ПАРИЖ, 9 гыйнвар. Кичә кич белән Парижда иглан ителгән рәсми белдерүдә фронтта „әйтерлек бер нәрсә дә булмаганлык" хәбәр ителә.

БЕРЛИН, 9 гыйнвар. Германия армиясенең верховный командованиесе болай дип белдерә: „Безнең авиациянең Төньяк диңгезнең төньяк өлешендә җирле разведка хәрәкәтен һәм очышлар ясавын искә алмаганда— әйтерлек бер нинди вакыйга дә булмады".

ЛОНДОН, 9 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгы, гыйнварның беренче атнасында диңгездәге сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә Англиянең ике пароходы, Норвегиянең бер һәм Швециянең ике пароходы батырылганлыкны тапшыра.

Шул ук агентлыкның хәбәр итүенә караганда, Германия самолеты, уйлауларына караганда „Гейнкель" самолеты булса кирәк, Төньяк диңгездә Англия танкерына 3 бомба ташлаган. Бомбаларның берсе танкерга бик якын төшкән һәм машина бүлегенә зиан китергән, радиостанцияне сафтан чыгарган. Англия танкеры немец самолетына ут ачкан. Самолет шунда ук болыт арасына кереп качкан.

НЬЮ-ЙОРК, 9 гыйнвар. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Рио—де—Жанейродан хәбәр итүенчә Англиянең Ливерпульдан килгән пассажир пароходы „Хәйләнд пейтриот" командасының һәм пассажирларының белдерүенә караганда, 23 нче декабрьдә ул Канар атаулары якынында Германиянең су асты көймәсенә каршы сугышкан. Пассажирларның һәм пароход командасының кешеләрнең берсенә дә зарар килмәгән.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Кантоннан төньякта кытай гаскәрләре Кантон—Ханькоу тимер юлы буйлап чигенүче японнарны эзәрлекләүне дәвам иттерәләр.

Гуандун провинциясенең көнчыгыш өлешендә Чаочжоу районында булган сугышларда японнар ике көн эчендә 500 ләп кешеләрен югалтканнар

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Соңгы көннәрдә Хунань провинциясенең төньяк өлешендә Иочжоуга кытай гаскәрләренең һөҗүме яңартылган.

6 нчы гыйнварда японнарның 3 мең кешелек отряды Хенань провинциясенең көньяк өлешендә Синьяннан 40 километр көньяк-көнбатыштарак һөҗүм башлаган. Отрядның 20 орудиесе, 18 броневигы һәм берничә самолеты бар.

Японнарның тылында Лучжоу секторында сугышлар башланган. Японнарның юллары монда берничә тапкыр өзелгән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә Цюйво, Ичэн, Вэньси, Сясянь районнарында сугышлар бара.

Суйюань провинциясендә Баотоу өчен булган сугышлар вактында японнарның кавалерия полкы командиры полковник Оваранын үтерелгәнлеге мәглүм булды.

**

„Даиньэбао" газетасы 6 нчы гыйнварда Кантон—Ханькоу тимер юлында Кантоннан 70 километр төньяктарак Бацзян өстендә 14 кытай самолеты белән 9 япон самолеты арасында һавада сугыш булганлыкны хәбәр итә. Япон самолетлары зарарланганлыктан чигенергә мәҗбүр булганнар. Шуннан соң Кытай авиациясе Бацзяннан 20 километр көньяк-көнчыгышта японнарның сугыш объектларын бомбага тоткан.

АК ФИНЛЯНДИЯ „ДЕМОКРАТИЯСЕ" ТУРЫНДА НОРВЕГИЯ ЭКОНОМИСТЫ

СТОКГОЛЬМ, 9 гыйнвар. (ТАСС). „Ню даг" газетасында Норвегия экономисты—Иоганн Фогтның китабыннан өзекләр басып чыгарылды. Ул ак Финляндиядә маннергеймчылар тәртибен фаш итә.

Автор болай дип яза:

„Финляндиядә „демократия" дигән нәрсә бик кызганыч булып күренә. 1918 нче ел бу „демократия"нең үрнәге булып хезмәт итә ала. Ул вакытта Финляндиядә хөкем сөргән ак террор мәңгелек эзләр калдырды. Фин ак гвардеецлары 16 мең чамасы хезмәт иясен аттылар. 90 мең чамасы ирләр һәм хатын-кызлар төрмәләргә утыртылдылар; шулардан 15 мең кеше ачлыктан үлде. 75 мең кеше судка бирелде һәм 67 мең кеше төрмәгә хөкем ителде.

Финляндия хөкүмәте 1929 нчы елны ук профсоюзларны тараткан һәм аларның җитәкчеләрен төрмәләргә утырткан иде. 1930 нчы елны Финляндия социал-демократиясе үзенең яңа профсоюз оешмасын төзеде, ләкин революцион настроениеле эшчеләр аңа кермәделәр. Хәзер бу профсоюзлар барлык эшчеләрнең 10 процент чамасын гына берләштерәләр. Авыл хуҗалыгы эшчеләре арасында асылда профсоюз членнары юк. Финляндиядә үзләренең эшчеләренә газеталар, китаплар һ. б. укуны тыючы алпавытлар бар. Профсоюзга керергә теләүче һәрбер эшче алдына эшсез калу куркынычы килеп баса. Күп кенә заводларда эшчеләр урыннарыннан чыгарылуларын теләмәсәләр реакцион профсоюзларга член булып керергә тиешләр.

Финляндиядә 20 мең чамасы эшче эшчеләр хәрәкәтендә катнашканлыклары өчен барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгәннәр. Финляндия төрмәләрендә йөзләрчә политик тоткыннар яткырыла. Аларның хәле коточкыч. Аларны төрлечә мәсхәрәлиләр.

Фин халкының милли интересларын сатучы һәм чит ил дәүләтләре файдасына эш итүче фин сугыш чукмарлары итеге астына килеп эләккән Финляндиянең „демократия"се әнә шундый.

Фин сугыш чукмарлары таянычының—„Карелларның академик җәмгыяте" дип аталган нәрсәнең Советлар Карелиясен генә түгел, бәлки Төньяк Норвегия һәм Төньяк Швеция территорияләрен дә басып алырга пропагандалавы характерлы.

Англиядә чыга торган „Дейли уоркер" газетасын Франциядә эзәрлекләү

ЛОНДОН, 9 гыйнвар. (ТАСС). „Дейли уоркер" газетасының хәбәрчесе, Франция эчке эшләр министрлегенең ил эчендә компартияне һәм коммунистик матбугатны тыю белән генә канәгатьләнмичә Англиядә чыга торган „Дейли уоркер" газетасын Англиянең экспедиция көчләре солдатлары арасында таратуга каршы да чаралар күрүе турында яза. Күптән түгел генә Франция властьлары „Дейли уоркер" ны Франциядә сатуны һәм таратуны тыеп приказ чыгардылар. Хәбәрче: „Франция властьлары Англия солдатларының үзләре теләгән газеталарны уку хокукларын чиклиләр" дип яза. Күптән түгел генә Франция властьлары „Дейли уоркер" газетасын укучы солдатлар турында властьларга хәбәр итүне үтенеп инглиз офицерларына мораҗәгать иткәннәр.

Шаньдун провинциясендә Кытай партизаннарының хәрәкәте

ШАНХАЙ, 9 гыйнвар. (ТАСС). „Шэньчжоужибао" газетасының хәбәр итүенә караганда, Шаньдун провинциясендә кытай партизаннарының көчле активлыгы сизелә. Партизаннар Цзяочжоу—Цзинань линиясен өзгәннәр. Цзяочжоудан төньяк-көнбатыштарак Гаоми шәһәре берничә көн буена партизаннар кулында булган. Дэчжоу һәм Цзанчжоу районнарында японнар белән партизаннар арасында сугышлар бара.

Укытучы кино-картинасыннан бер кадр.

Кино

„УКЫТУЧЫ"

Социалистик җәмгыять кешеләре, аларның үсүләре турында, совет кешеләренең мәхәббәте, дуслыгы, хезмәте, тормышларындагы кичерешләре турында сөйли торган бу картина үзенең беренче кадрыннан ук тамашачыны үзенең эченә ала. Картинаны карый башлау белән тирә ягыңны онытасың. Москвада педагогик институтта укып, туган авылына кайтып килүче Степан Лаутин белән бергә авылга килеп керәсең, каршыга авыл балалары йөгереп киләләр, алар Степанны һәм тамашачыны Иван Лаутин өенә алып керәләр. Степан белән бергәләп, өйдәгеләргә Москва бүләкләре өләшәсең. Аннары Степан кайту хөрмәтенә Лаутиннар өендә ясалган кичәдә буласың...

— Минем сезнең янга, авылыма кайтуымның сәбәбе турындагы бер кадәр ялгыш фикерне төзәтеп үтәргә кирәк булыр ахыры,—ди Степан һәм үзенең бөтенләйгә кайтканлыгын, атаклы колхозга лаеклы яхшы мәктәп салдырырга һәм шунда эшләргә карар биргәнлеген аңлата.

Иван Лаутинга шул җитә кала. Кунаклар таралу белән ул Степанга ташлана:

— Димәк, булдыра алмадың, күтәрелә алмадың...

Ләкин карт ялгыша. Ул, совет кешеләренең очучы булып кына түгел, укытучы булып та, шәһәрдә генә түгел, авылда да коммунизм төзелеше эшенә гаять зур хезмәтләр күрсәтә алуларын төшенеп җитә алмаган иде әле.

Ә укытучы Степан чыннан да авылда культура ягыннан революция ясый. Аңа бик күп кыенлыкларны һәм шул исәптән үзенең белеме җитеп бетмәүне дә җиңәргә туры килә. Ул беренче дәрестә үк балаларны чын мәгънәсе белән коммунизм рухында тәрбияли алачагын күрсәтә. Ул, балаларга Чеховның „Ванька" исемле хикәясен укый. Хикәя бик гади. Патша Россиясендә изелеп яшәгән миллионнарның берсе—Ванька—шәһәрдә малайлыкта хезмәт итүче бала—үзенең авыр тормышыннан зарланып, авылдагы бабасына хат яза: „Ходай хакы өчен мине алып кит, мин нинди генә авырлыкларга да риза булырмын, тик мондагы авырлыкларны гына күрмәсәм иде" ди. Аннары, конверт тышына „Авылга, Бабайга. Константин Макарычка" дип адрес яза да, почта ящигенә сала. Чеховча—хат тапшырылмаган. Ләкин...

— Бу хат барып җиткән, иптәшләр. Ул, бабай кулына тапшырылмаган... Ул башка кеше кулына эләккән... Бу кеше, башка байларны бәреп ташлаган кебек, Алхяин байны да бәреп ташлады... Бу кешенең исме Владимир Ильич Ленин.

Әнә шулай итеп, Степан башта ук балаларның йөрәгендә кешелек дөньясының бөек даһиена, димәк коммунистлар партиясенә карата мәхәббәт ялкыны кабыза.

Степан авылда үзе кебек яңа, яш интеллигентларны, совет интеллигентларын тудыра. Аларның беренчесе—Аграфена Шумилина. Аның күкрәген бизәп торган орденны аның ни өчен алганлыгы да билгеле түгел. Ләкин аның орденлы булуы бик табигый. Чөнки безнең илебездә һәр кем орден белән бүләкләнергә лаеклы. Тик үз-үзеңне аямау гына, чын күңелдән бирелеп эшләү генә кирәк. Укый-яза белүдән башка белеме булмаган Груня зур һәм җаваплы темага сынаудан үтәрлек дәрәҗәгә кадәр күтәрелә...

Степан авылга кайту белән аның белән Аграфена арасында мәхәббәт башлана һәм ул торган саен тирәнәя бара. Ләкин бу элекке мәгънәдәге мәхәббәт түгел. Бу яңа мәхәббәт. Бу—күңелле, матур, тигез тормыш белән төгәлләнәчәк мәхәббәт.

Степан Лаутинның колхозда зур мәктәп салдыру турындагы хыялы тормышка аша. Ул, чыннан да авылда культура революциясе ясый. Һәм Совет иле, совет халкы аның күрсәткән хезмәтләренә тиешле бәяне бирә: ул Верховный Советка депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелә. Тик шушында гына Иван Лаутин үзенең ялгышканлыгын аңлый һәм улына булган карашын үзгәртә.

— Иптәшләр, бу минем улым бит,—ди ул.

Картина турында тулы итеп язу өчен газета мәкаләсендә генә урын җитмәячәк. Аны үзең күрергә, андагы геройлар белән берлектә, алар үткәргән кичерешләрне үзең үткәрергә кирәк.

Укытучы ролендә республиканың атказанган артисты орденлы Б. Чирковның, Груня ролендә орденлы артистка Тамара Макарованың, геройлыкны яратучы, эшлекле, тынгысыз, карт партизан, колхоз председателе Иван Лаутин ролендә П. Волковның, Степанның сеңлесе Маня ролендә Л. Шабалинаның, шулай ук башка артистларның да бирелеп, тырышып уйнаулары картинаны тагын да җанландыра.

Сценарист һәм постановщик Сергей Герасимов үзенең бурычын бик яхшы аңлап, үтәп чыга алган дияргә генә кала.

Төхфәт.

ЛЕНИН КӨННӘРЕНӘ ХӘЗЕРЛЕК

ВКП(б) ның Баулы район комитеты район үзәгендәге партия кабинетында В. И. Лениннең тормышын һәм революцион эшен күрсәткән әдәбият һәм документлардан күргәзмә оештырды. Шушындый ук күргәзмәләр Сталин, Куйбышев исемендәге колхозларда һәм Поповский МТС ында һәм башка колхозларда да оештырылды.

178 беседачы В. И. Лениннең тормышы һәм революцион эше турында район күләмендә беседалар алып баралар. ВКП(б) райкомының бюросы Ленин көннәрендә докладлар ясау өчен 49 докладчы билгеләде. Алар, „Иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлыннан Ленинсез 16 ел", „Дәүләт турында Ленин—Сталин өйрәтүләре", „Ленин һәм Сталин ВКП(б) ны оештыручылар һәм аның җитәкчеләре" дигән темаларда докладлар ясаячаклар.

В. И. Ленинга багышланган күргәзмә

Казан Дәүләт университеты янындагы фәнни көтепханә пролетариатның бөек даһие Владимир Ильичкә багышланган күргәзмә оештыра. Күргәзмәдә Ильичнең балалык, яшьлек елларына шулай ук революцион эш алып бару елларына киң урын бирелә. Лениннең Казан университетында укыган еллары, шулай ук университетта студентлар сходкасы оештыруы җирле материаллар белән яктыртылачак.

Күргәзмә көтепханәнең уку залында 15 нче гыйнварда ачыла.

Ильичне искә алу кичәләре

21 нче гыйнварда Казан укытучылар йортында шәһәр укытучыларының Владимир Ильич Ленинне искә алуга багышланган кичәсе үткәрелә. Кичәдә В. И. Лениннән башка 16 ел дигән темада доклад куела. Докладтан соң Татарстан Дәүләт филармониясе артистлары тарафыннан тематик концерт бирeләчәк.

24 нче гыйнварда балалар өчен Ильичкә багышланган иртәлек үткәрелә

***

Совет Сәүдә Работниклары Клубы 21 нче гыйнварда сәүдә работникларының Владимир Ильич Ленинне искә алу җыелышын үткәрә. Җыелышта „иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлыннан Ленинсез 16 ел" дигән темада доклад булачак. Докладтан соң клубның үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан тематик концерт биреләчәк.

БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты түбәндә фамилияләре күрсәтелгән иптәшләрнең, сөйләшү өчен, эш сәгатьләрендә 20 нче бүлмәгә килүләрен сорый:

Иван Павлович Мекшис—элек 27 нче заводта шофер булып һәм аннан соң 14 нче трестта эшләгән.

Мөфәхәр Закиров—элек Татнаркомземда дәүләт санитария инспекциясе начальнигы булып эшләгән.

Габдрахман Сәет улы Насыров—ВКП(б) ның Бауман район комитетында учетта торган.

Сөләйман Кәшаф улы Баһаветтинов—элек Татарстан АССР Наркомлегпромының җәмагать туклану бүлеге начальнигы булып эшләгән.

Кузьма Семенович Романов — элек Молотов райконторасында снабсбыт начальнигы булып эшләгән.

Григорий Иванович Ронжин — Казан Авиация институты студенты булган.

Мария Петровна Скорнякова—элек Татваленкада эшләгән.

Алексей Романович Потапов—элек ИТК № 1 нең хуҗалык бүлегендә эшләгән.

Митрофан Иванович Петров—элек тимер юлның Казан станциясендә үлчәүче булып эшләгән.

Василий Михайлович Максимов — элек Глававтотракторсбытта эшләгән.

Федор Георгиевич Бирюков—элек Мединститут төзелешенең начальнигы булып эшләгән.

Гатаулла Гали улы Шәрифуллин—элек Ленин исемендәге заводда эшләгән.

Иван Сергеевич Сорожкин—элек Ленин исемендәге заводта эшләгән.

Югарыда фамилияләре күрсәтелгән иптәшләрнең тору яисә эшләү урыннарын белүче гражданнардан,—ул турыда ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетына белдерүләре сорала.

Җаваплы редактор

Һ. АБДРАХМАНОВ.

Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫНЫҢ

Юллар Санитария-Гигиена лабораториясе

(Казан, Посадск урамы, 10)

һәр төрле азык продуктларын, ашларны, суларны һәм эчемлекләрне химик-бактериологик анализлау

һәм корсак тифы, тимгелле тиф, бруцеллез бацилларына карата химик-бактериологик анализлар эшләре үткәрү, шулай ук фәнни тикшеренү эшләре үткәрү буенча барлык кызыксынган оешмалар һәм учреждениеләр белән

ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ

2719—2—2

Барлык гражданнар игтибарына!

ГОРПРОМТОРГНЫҢ 13 НЧЕ МАГАЗИНЫ

„Сатып алынган һәм комиссионный товарлар сату-урнаштыру буенча

ГОРПРОМТОРГ базасы" ДИП ЯҢАДАН ИСЕМЛӘНДЕ

Базаның шәһәрдә сату-урнаштыру пунктлары:

№ 1—Бауман урамы 9—10—11 нче йортларда. Телефон 23—40.
№ 2—Куйбышев урамындагы 7 нче йортта.
№ 3—Киров урамындагы 64 нче йортта.
№ 4—Сталин районындагы 1 нче базарда.
№ 5—Суконный базарында.
№ 6—Чехов базарында.

2788—2—2 Горпромторг дирекциясе.

Югары Волга Пароходчылыгының

КАЗАН ПРИСТЕНЕ

1940 нчы елның пароходлар йөрү сезонында су юлы белән, тиз йөртелергә тиешле йөкләрне ССР Союзының барлык урыннарына, ә нормаль тизлек белән йөртелергә тиешле йөкләрне Казан пристене районына кергән урыннарга йөртү буенча 1940 нчы елның 1 нче гыйнварыннан

ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ БАШЛАДЫ

Договорлар төзү 1940 нчы ел 20 нче февральгә кадәр дәвам итә. Договор төзегән оешмаларның йөкләре беренче чиратта төяләп җибәреләчәк. Күрсәтелгән срокта договор төземәгән оешмалардан һичбер нинди дәгъвалар алынмаячак.

2683—2—2 Дирекция.

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы автоуправлениегә караган

АВТОМӘКТӘП

III нче класс шоферлар хәзерләү буенча хатын-кызлардан

УКУЧЫЛАР АЛА

Шоферлар хәзерләү курсларына керүчеләрдән түләү алынмый.

Курсларда укулар шушы ел 10 нчы гыйнварда башлана.

Казан, Свердлов урамы, 40. Телефон 9—86.

22—1

Казан шәһәре Молотов районындагы 323 нче йорт идарәсенең урланган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга.

40—1

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның

ФЗУ МӘКТӘБЕ

15 тән 18 гә кадәр яштәге һәм җиде еллык мәктәпне тәгәлләгән үсмерләрдән

УКУЧЫЛАР АЛА

Гаризалар 1940 нчы ел 1 нче гыйнвардан 15 нче гыйнварга кадәр алына.

Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, тулы булмаган урта мәктәпне тәгәлләү турында бирелгән аттестат, яше турында документ һәм сәламәтлеге турында медицина белешмәсе бирелергә тиеш. Болардан тыш паспорт күрсәтелә.

Гаризалар мәктәп директоры исменә бирелә. Мәктәпкә алынганнарга, аларның теоретик һәм практик өлгерешләренә карап, айга 75 сумнан 150 сумга кадәр стипендия бирелә.

Укулар 1940 нчы ел 1 нче февральдән башлана.

Белешмәләр ял көннәреннән башка һәр көн көндезге 12 сәгаттән 4 кә кадәр ФЗУ мәктәбенең укыту бүлегендә бирелә.

Дирекция.

2660—2—2

Казандагы сөт тикшерү станцияләрендә эшләү өчен лаборантлар хәзерләү буенча

Горздрав тарафыннан

3 АЙЛЫК КИЧКЕ КУРСЛАР АЧЫЛДЫ

Курсларга 7 еллык мәктәпне тәгәлләгән кешеләр алыналар

Белешү өчен адрес: Казан, Чернышевский урамы, 2, дүртенче кат, 108 нче бүлмә.

39—1

38 нче трестның 9 нчы конторасы „М—1" маркалы

җиңел автомашина сатып ала

яисә үзенең йөк автомобиле белән алмаша

Тәкъдимнәр һәм белешмәләр 4—75 телефоны буенча була ала.

23—2—1

ВАХИТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ЖИРКОМБИНАТНЫҢ

ФЗУ МӘКТӘБЕ

мәктәпнең хәзерлек группасына (руслар группасы)

УКУЧЫЛАР АЛА

Хәзерлек группасына 7 класс күләменнән түбән белемле һәм 16 дан түбән булмаган яштәге үсмерләр алыналар.

Гариза белән бергә, керүченең яше турында документ, мәктәптән, ата-анасының эшләгән урыннарыннан бирелгән һәм чәчәк салынган булу турында белешмәләр бирелергә тиеш.

Укулар 1940 нчы ел, 15 нче гыйнвардан башлана.

Тулай торак булмый. Вак-төяк расходлар өчен кечкенә стипендия бирелә. Казан, Тукай урамы, 113. Жиркомбинат техникумы бинасы (3 нче маршрут трамваеның Вахитов исемендәге завод янындагы тукталы). 2680—3—2

Главлесосбыт Казан конторасының

ЛЕСОБРАКЕРАЖ КОНТОРАСЫ,

расланган бәяләрдән, һәр төрле

агач материалларына —экспертиза үткәрә—

Казан, Колхоз урамы, 13. Телефон 13—65.

46—2—1

Казан Дәүләт Мединституты студентларын урнаштыру өчен ашыгыч рәвештә

БҮЛМӘЛӘР һәм почмак урыннар КИРӘК

Түләү килешү буенча. Тәкъдимнәр җибәрү өчен адрес: Казан, Университет урамы, 13.

44—2—1

„Трансэнергокадр" ның Казан бүлегенә

инженер тепло-техник эшләре инженеры кирәк

Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Банк урамы, 15. 2563—2—2

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

Бүген спектакль булмый.

12 нче гыйнварда көндез (талон 93)

ГАЕПСЕЗДӘН ГАЕПЛЕЛӘР

Кич (талон 94)

КЫЮ КЫЗЛАР

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

11, 12 һәм 13 нче гыйнварда М. Ю. Лермонтовның тууына 125 ел тулуга багышланган юбилей спектакльләре

МАСКАРАД

Бүген талон 74.

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Тулысынча яңа программа

Москва 4 нче труппасының гастрольләре

Бөтен труппа катнаша.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры

Татар Дәүләт Академия театры бинасында 11 нче гыйнварда

КАЧКЫН

Талон 63.

Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.

Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына. Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.

48—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 11-45, 1-45, 3-45, 5-45, 7-45 һәм 9-45 тә.	Көндез 10 сәгатьтә **ҺАВА ПОЧТАСЫ** һәм башка сеансларда **УКЫТУЧЫ**
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	**УКЫТУЧЫ** Көндез 10 сәгатьтә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда **МИТЬКА ЛЕЛЮК** Кич **УКЫТУЧЫ**
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	**СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН**
„ПИОНЕР" 11, 2, 4, 5-45 8 һәм 10-15 тә	Көндезге сеансларда **ПАРТИЗАН КЫЗЫ** Кичке сеансларда **БӨЕК ГРАЖДАНИН** (икенче сериясе) Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс
„РОТ-ФРОНТ" 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	**Бөек бүләк**
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	**ТАУ МАРШЫ**

„Химзаготлес" трестының агач хәзерләү буенча районара Казан конторасына, баш контора аппаратында эшләү өчен, эшбашкаручы, автомеханик, производство бүлеге начальнигы, планнар бүлеге начальнигы һәм автотранспорт белән таныш механизация инженеры КИРӘК. Хезмәт хакы килешү буенча. Кирәк булса, белгечләргә тору урны бирелә. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Зур урам, 62, кадрлар бүлеге. Телефон 42—06.

2542—2—2

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 207 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 135.